**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«НОВОТРОИЦК» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«01» декабрь 2021 ел № вн-1/1

**«Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 22 августындагы 19/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 5, 394 һәм 397 статьялары, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 22 августындагы 19/1 номерлы карарына (2017 елның 28 декабрендәге 24/2, 2018 елның 24 сентябрендәге 30/1, 2018 елның 30 октябрендәге 31/1, 2019 елның 8 ноябрендәге 41/2, 2020 елның 27 мартындагы 44/1, 2021 елның 02 апрелендәге 10/1 номерлы карарлар үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктка пуктча өстәргә:

«11) «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән махсус оешмалар милкендә булган җир кишәрлекләренә карата 0,001.».

2. Әлеге карарның 1 пункты 1.1 пункты рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ю.М. Рыбакова